**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ СӘФӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423748, Иске Сэфэр авылы, М.Вахитов ур., 16 нчы йорт. Тел.3-44-55

**СОВЕТ СТАРОСАФАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423748, село Старое Сафарово, ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 3-44-55

КАРАР РЕШЕНИЕ

от 18.12.2020г. № 11

**Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлегенең 2021 елга 2022 һәм 2023 елларның план чорына бюджеты турында**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетының 2021 елга төп характеристикаларын расларга:

1.1. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 3094,55 мең сум итеп;

1.2. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 3094,83 мең сум итеп.

1.3. Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты дефицитының иң чик күләмен 0 мең сум итеп.

2. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетының 2022 елга һәм 2023 елга төп характеристикаларын расларга:

2.1. Иске Сәфәр авыл җирлегенең 2022 елга фаразланыла торган керем күләмен 27940,2 мең сум һәм 2023 елга 28290,5 мең сум күләмендә;

2.2. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетының 2022 елга чыгымнар күләме 27940,2 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар - 698 мең сум һәм 2023 елга 28290,5 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар - 1397 мең сум күләмендә.

2.3. Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлегенең 2022 елга бюджет дефицитының иң чик күләме 0 мең сум һәм 2023 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә.

4. 2022 елның 1 гыйнварына Иске Сәфәр авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча иң югары чикне 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4.1. 2023 елның 1 гыйнварына Иске Сәфәр авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4.2. 2023 елның 1 гыйнварына Иске Сәфәр авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум, шул

исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум билгеләргә.

4.3. Иске Сәфәр авыл җирлеге муниципаль бурычының иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

- 2021 елда - 0 мең сум күләмендә;
- 2022 елда - 0 мең сум күләмендә;
- 2023 елда - 0 мең сум күләмендә.

5. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, 2021 елга 2022 һәм 2023 елларның план чорына фаразлана торган керемнәр күләмен исәпкә алырга.

6. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген 3 нче кушымта нигезендә расларга.

7. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген 4 нче кушымта нигезендә расларга.

8. 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

9. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

10. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

11. Иске Сәфәр авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне түбәндәгечә карарга:

- 2021 елда 13568,8 мең сум күләмендә;
- 2022 елда 12918,6 мең сум күләмендә;
- 2023 елда 12911,4 мең сум күләмендә.

Совет Рәисе,
Иске Сәфәр авыл җирлеге башлыгы Г.З.Сайфутдинова